ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының $6^1$ һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2007, № 8; 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 4 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 1 – 2; 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 94 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $6^1$ статьяда «Россия Федерациясенең бухгалтерлык хисабы турындагы законнарында аның мәҗбүри нөсхәсен» сүзләрен «, әгәр күрсәтелгән предприятиеләр һәм җәмгыятьләр мондый хисаплылыкны «Бухгалтерлык исәбе турында» 2011 елның 6 декабрендәге 402-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясында каралган дәүләт мәгълүмат бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы ресурсын (алга таба – дәүләт мәгълүмат бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы ресурсы) формалаштыру максатларында тапшыру бурычыннан азат ителгән булса, Россия Федерациясенең бухгалтерлык хисабы турындагы законнарында аның мәҗбүри нөсхәсен тапшыру өчен билгеләнгән срокта, шулай ук» сүзләренә алмаштырырга, «тапшыру өчен билгеләнгән срокта» сүзләрен төшереп калдырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Күрсәтелгән предприятиеләр һәм җәмгыятьләр дәүләт мәгълүмат бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы ресурсын формалаштыру максатларында еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын тапшырган очракта, вәкаләтле башкарма хакимият органы мондый хисаплылыкны, бердәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасын кулланып, дәүләт мәгълүмат ресурсыннан ала.»;

2) 11 статьяның сигезенче абзацында «бухгалтерлык балансын, табышын һәм зыяннары исәпләрен» сүзләрен «еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 30 сентябрь
№ 61-ТРЗ